**РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом17,с. Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ЖИТӘКЧЕСЕ**

Ленин пр.,17йорт,Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-02-22,факс (85552) 3-13-44, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ 21.09.2021 КАРАР
______________ ПР-189 № _______

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясе буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрын җайга салынмый торган тарифлар буенча раслау турында

«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясе буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрын кушымта нигезендә җайга салынмый торган тарифлар буенча расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә:

2.1. Актаныш муниципаль районы территориясе буенча пассажир транспортының автобус маршрутлары хәрәкәте графигын билгеләнгән тәртиптә расларга;

2.2. җайга салынмый торган тарифлар буенча муниципаль маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклыклар һәм тиешле маршрутлар карталарын алу хокукына ачык конкурс үткәрергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://aktanysh.tatarstan.ru үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 0281778300DAAC80B04F73F8D6671EB6BC
Владелец: Габдулхаев Ильшат Ильфатович
Действителен с 25.02.2021 до 25.05.2022

И.И.Габдулхаев

Лист согласования к документу № ПР-189 от 21.09.2021
Инициатор согласования: Салимов Д.З. Начальник юридического отдела
Согласование инициировано: 21.09.2021 09:02

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Салимов Д.З. | | Согласовано<br>21.09.2021 - 09:02 | - |
| 2 | Габдулхаев И.И. | | Подписано<br>21.09.2021 - 13:20 | - |